## IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГЕЛДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ XXXXI УТЫРЫШЫ

## КАРАР № 72

Тойгелде авылы «20» июнь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге территориясендә төзеклəндерү өлкəсендəге муниципаль контроль турындагы нигезлəмəне раслау хакында»гы 2021 елның “19” нчы ноябрендəге 27 нче номерлы карарына үзгəрешлəр кертү хакында**

Россия Федерациясе Федераль законнарына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Тойгелде авыл җирлеге территориясендə төзеклəндерү өлкəсендəге муниципаль контроль турындагы нигезлəмəне раслау хакында» гы 2021 елның “19” нчы ноябрендəге 27 нче номерлы карарына түбəндəге үзгəрешне кертергə:

1.1. 1.7 пунктының 1 пунктчасын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«1) планлаштыру структурасы элементлары (зоналар (массивлар), районнар (шул исəптəн торак районнар, микрорайоннар, кварталлар, сəнəгать районнары), яр буйлары, гражданнарның бакчачылык, яшелчəчелек һəм коммерциягə карамаган берлəшмəлəрен урнаштыру территориялəре;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мəгълүматының рəсми порталында Интернет мəгълүмат-телекоммуникация челтəрендə бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль берəмлегенең рəсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рəсми рəвештə игълан ителгəннəн соң үз көченə керə.

4. Әлеге карарның үтəлешен контрольдə тотуны үз өстемə алам.

Тойгелде җирлеге
башлыгы урынбасары Минһаҗева Г.Р.